**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **15.11.2023ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлеге Юртау торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 15.11.2023 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре белән халык җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:«2024 елда Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Юртау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру (тукталыш пункты);

- Юртау бистәсендә җәйге вакытта территориядә үлән чаптыру(ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 285 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 152 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 152 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районының Юртау авылы җирлегенең Юртау торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карар кабул ителде дип танырга:«2024 елда Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге Юртау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә

ризамы,1 һәм 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияле һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- тукталыш павильонын сатып алу һәм урнаштыру (тукталыш пункты);

- Юртау бистәсендә җәйге вакытта территориядә үлән чаптыру(ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Юртау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ menzelinsk.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлеге башлыгы: И.Ю.Кадыров